ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

04.08.2020 ел Баулы шәһәре №156

«Баулы муниципаль районында мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 15 мартындагы 66 номерлы карарына (2016 елның 31 гыйнварындагы 16 номерлы, 2020 елның 6 апрелендәге 75 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү хакында

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2020 елның 07 июлендәге 01-51/4582 номерлы хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 15 мартындагы 66 номерлы карарына (2016 елның 31 гыйнварындагы 16 номерлы, 2020 елның 6 апрелендәге 75 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Муниципаль учреждениеләргә, муниципаль казна предприятиеләренә оператив идарә итү хокукында һәм муниципаль унитар предприятиеләргә хуҗалык алып бару хокукында муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты” 26нчы кушымта үз көчен югалткан дип танырга;

27, 28, 29, 30, 31, 32, 33, 34нче кушымталарны 26, 27, 28, 29, 30, 31, 32, 33нче кушымталар дип санарга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров